# «ӨММИ КАМАЛ КИТАБЫ»НЫҢ ЯҢА БАСМАСЫ

***Исламов Р.Ф.,*** *филология фәннәре докторы,*
***Габдулхакова Г.М.***

# NEW EDITION OF THE «BOOK OF UMMI KAMAL»

***Islamov R.F., Gabdulkhakova G.M.***

Өмми Камал (чын исеме – Исмәгыйль) – XV гасыр башы Идел-Урал буе татар язма мәдәниятен, аерым алганда, суфичылык әдәбиятын үстерүгә сизелерлек өлеш керткән шагыйрьләрнең берсе. Бу хакта аның әсәрләренең әйтеп үтелгән төбәктә элек тә киң таралган булуы ачык сөйли. Әйтик, хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең Шәрык кульъязмалары бүлегендә, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, Казан Милли китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә[1], Россия Фәннәр академиясенең Санкт-Петербург Көнчыгышны өйрәнү институтында[2], Россия Фәннәр академиясенең Уфа тикшеренүләр үзәге Тарих, тел һәм әдәбият институты фондында[3] текстларның шактый күчермәләре саклана. Дөрес, аларның барысы да тулы түгел һәм язылган кәгазьләренең сыйфатлары да төрлечә.

Шагыйрь әсәрләренең «Өмми Камал», «Өмми Камал китабы» дигән җыентыклары типография ысулы белән 1884[4], 1898[5], 1899[6], 1906[7] елларда Казан матбагаларында нәшер ителә. Кайбер чыганакларда бер нөсхәсенең 1897 елда да дөнья күрүе турында язалар. Ләкин бу дөрес түгел. Ул – 1898 елгы басмага цензура тарафыннан рөхсәт бирелү датасы.

Китапларның ахырында татар суфи шагыйре Әбелмәних Карагалиның (1782–1833 тән соң) кайбер шигырьләре дә урнаштырылу бер дә юктан гына түгел.

Кызганыч ки, Өмми Камалның шәхесе турында мәгълүмат сакланмаган. Шигырьләрендә дә бу хакта бернинди хәбәр китерелми. Бары тик тексттагы «Колларың кәмтәридер Исмәгыйль / Нә вар Өмми Камал исә ләкаби» дигән шигъри юллардан без аның чын исемен һәм әдәби тәхәллүсен генә беләбез. «Гарибәм, горбәтә кәлдем илемдән» дигән икенче шигъри юлында ул үзен читтән килгән, ягъни горбәттә яшүче итеп күрсәтә. Димәк, шагыйрь Идел-Урал буйларына башка җирдән килеп яшәгән һәм иҗат иткән.

Кумык галимнәре бернинди дә чыганакны күрсәтмичә аны урта гасырдагы Коюнкала шәһәрендә туган һәм Төркиядәге Конья шәһәрендә

вафат булган дип язалар[8] һәм шагыйрьне фәкать үзләренеке генә дип белдерәләр.

Өмми Камалның тормышын һәм иҗат мирасын татар әдәбияты гыйлемендә өйрәнә башлау барыннан да элек галим һәм язучы М. Гали (1893–1952) исеме белән бәйле. Ул 1941 елда «Совет әдәбияты» журналының 5 нче санында аңа багышланган күләмле мәкалә бастыра[9]. Анда әсәр турында гомуми мәгълүмат китерелә, шагыйрьнең идеологиясе һәм тормышка карашы ачыклана, текстта табигать күренешләренең тасвирланышы яктыртыла, шигырь төзелеше һәм образларның сәнгати бирелеше тикшерелә, тел мәсьәләләренә игътибар ителә, авторга үзеннән элгәреге әдипләрнең тәэсире, аның борынгы һәм аннан соңгы татар шигъриятенә йогынтысы хакында языла. Ахырда шундый нәтиҗә ясала: «...Без Өмми Камалны татарның борынгы чор шагыйрьләре сафына кертергә, хәтта аны саннары дистәдән узган ул чор шагыйрьләре тезмәсенең беренче төймәсе итеп куярга да хакыбыз бардыр дип беләм»[10].

Алга таба «Борынгы татар әдәбияты» дип аталган күмәк хезмәттә Өмми Камал турында зур булмаган мәгълүмат китерелеп, аның «Мөнаҗате зәгыйфә» исемле шигыре нигезендә тормышы белән бәйле кайбер моментлар ачыклана: «Ләкин шагыйрь, материаль яктан мохтаҗлыкта яшәп, фаҗигале шәхси тормыш кичерә: балигъ булган улы үлә, бердәнбер сөекле кызы бәхетсезлеккә очрый, үзе котылгысыз авыру белән газаплана»[11].

Алты томлык «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томында шагыйрь хакында китерелгән мәгълүмат үзенең эчтәлеге белән «Борынгы татар әдәбияты»ндагысыннан әллә-ни аерылмый[12].

Профессор Х. Миңнегулов үзенең тикшеренүләрендә, Өмми Камал иҗатына да билгеле бер урын биреп, әсәрләренә кызыклы гына анализ ясый һәм шундый нәтиҗәгә килә: «Гомумән, Өмми Камал иҗаты – Ясәви, Бакырганый, Хисам Кятибләрдән килә торган әдәби традицияләрне дәвам иттерүдә, үстерүдә һәм баетуда мөһим буын. Үз чиратында ул үзеннән соңгы татар әдипләренә зур йогынты ясады»[13].

Шагыйрь турында кыскача белешмә һәм аның иҗатыннан үрнәк «Татар поэзиясе антологиясе»нә[14], татар[15] һәм башкорт[16] энциклопедияләренә кертелде.

Өмми Камал башкорт әдәбияты яссылыгында да өйрәнелә. Алты томлык «Башҡорт әҙәбиәте»нең беренче томында аңа махсус мәкалә багышланган[17]. Аерым алганда, анда шагыйрь иҗатының суфичылык поэтикасы тәфсилле яктыртыла. Аерым мисал нигезендә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасына барып тоташа торган бәйләнешнең бер традиция үрнәге күрсәтелә.

Әдәбият галиме Х. Миңнегулов Өмми Камалның иҗат мирасын тиешле дәрәҗәдә өйрәнергә кирәклеге хакында борчылып болай язган иде: «Кыскасы, Өмми Камал иҗатын татар әдәбияты контекстында карау урынлы һәм зарури күренеш. Әмма, кызганыч ки, бу талантлы

шагыйрьнең иҗаты махсус рәвештә бөтенләй диярлек тикшерелгәне юк. Әсәрләре дә хәзерге укучылар игътибарыннан һаман да читтә кала килә»[18].

Ниһаять, Уфа шәһәрендә яшәүче татар әдәбияты галиме Ф. Фәтхтдинов, шагыйрьнең иҗат мирасын эзлекле рәвештә махсус өйрәнеп, бу юнәлештәге эшне яңа баскычка күтәрде. Әүвәл этрафлы мәкаләләр бастырды[19], аннары кандидатлык диссертациясе язып яклады[20], соңыннан монография нәшер итте[21], уку әсбабы төзеде[22]. Максатчан эшнең уңышлы нәтиҗәсе буларак, быел Өмми Камал шигырьләренең гамәлдәге татар хәрефләрендә текстологик эшләнгән яңа басмасын нәшер итте[23].

Иң элек ассызыклап шуны әйтергә кирәк: басманың кереш өлеше һәм фәнни мәкаләләре ике телдә, ягъни русча һәм татарча бирелү хезмәт белән киң даирә укучылар таныша алу мөмкинлеген арттыра. Хезмәт авторы «Өмми Камал шәхесе һәм иҗаты турындагы карашлар, аларга фәнни мөнәсәбәт мәсьәләсе» дип аталган беренче бүлектә Өмми Камал һәм аның иҗат мирасының өйрәнелү торышына эзлекле рәвештә анализ ясый. Аерым алганда, татар, башкорт һәм төрек галимнәре М. Гали, Ш. Абилов, Г. Хөсәенов, В. Кожатөрек, Х. Миңнегулов, Р. Тляшев, Ф. Яхин хезмәтләрен тикшерә. Бу очракта ул гади констатацияләү ысулы белән эш итми, ә аларга карата үзенең объектив мөнәсәбәтен белдерә. Әйтик, шагыйрьнең вафаты хакында фәндәге төрле фикерләрне барлап чыкканнан соң, Хуҗа Сад-реддин исемле шәехкә багышлап язылган мәрсиядәге мәгълүматка нигезләнеп, 1475 елның дөреслеккә туры килүен раслый.

Өмми Камалның әлегәчә фәндә билгеле булмаган кулъязма китабы табылу – шагыйрьне өйрәнү юнәлешендә мөһим яңалыкларның берсе. Хезмәттә хәбәр ителгәнчә, ул, Башкортстанның Күгәрчен районында гомер итеп, туган якны өйрәнүче Нигъмәтулла Ваһаповта сакланган.

Өмми Камал әсәрләренең тел үзенчәлекләренә килгәндә исә, хезмәттән күренгәнчә, лексик яктан борынгы төрки сүзләрнең төп катламны тәшкил итүе, әмма гарәп-фарсы теленнән кергән сүзләрнең дә шактый булуы ачыклана. Гомумән алганда, «Шагыйрь иҗатында шул чор матур әдәбият стиленең төрки поэтик традицияләре саклана, шушы телнең үзенә генә хас сыйфатлары үсеш ала»[24].

Галим, әсәрләрнең кулъязмалары турында сүз алып барып, алар арасында яхшы сакланган һәм аңлаешлы ысул белән Сафакүл мәдрәсәсендә 1837 елда күчерелгән тулы нөсхәне билгели[25].

Алга таба икенче бүлектә Өмми Камал иҗатының төп нигезләре тикшерелә һәм шагыйрь поэзиясе фәлсәфи-эстетик нигезләренең мөселман Көнчыгышы, Идел-Урал буе әдәби казанышлары, бигрәк тә ул казанышларның суфичылык фәлсәфәсе белән тыгыз үрелеп баруы ачыклана. Әдип хыялый бер дәрвиш сурәтендә түгел, чынбарлык тормышка фәлсәфи караш беләш яшәүче тарихи шәхес буларак күзаллана.

Хезмәт авторы билгеләп үткәнчә, «Өмми Камал эзләнүчән кеше буларак, еш кына суфичылык поэзиясенең традицион темаларына мөрәҗәгать итә. Ләкин аның таланты коры тәгълиматлар, суфичыл вәгазь-нәсыйхәтләр кысасыннан читкә чыга, иҗаты реаль тормыш чынбарлыгыннан алынган күренешләр, җанлы кичерешләр белән сугарыла»[26]. Болар, мәсәлән, карендәшләргә, ата-анага, игенчелек кәсебенә багышлап язылган шигырьләрендә ачык чагылыш тапкан. Кеше гомеренең баскычлары табигатьтәге үсеш-үзгәреш процесслары аша фәлсәфи тасвиралана. Дөньяның нигезен тәшкил иткән *туфрак, су, ут* һәм *һава* шагыйрь иҗатында җанлы итеп сурәтләнгән һәм бу, галим язганча, аның иҗатында үзгә яңгыраш.

Галим, Өмми Камал шигырьләренең жанр үзенчәлекләрен тикшереп, әсәрләренең күпчелеген *тәүхид, хикмәт, газәл, мәрсия, мәдхия, мөнәҗәт* тәшкил иткәнлеген ачыклый һәм аларның шагыйрь иҗатындагы хосусиятләрен билгели.

Хезмәт авторы, әсәрләрдә чагылыш тапкан символлар турында сүз алып барып, болай яза: «Шагыйрь иҗатында дөнья – чәчәкле-гөлле *Гөлстан*, үтеп чыга алмаслык куе *Урман*, тукталып кына китә торган *Кәрвансарай*, кунакка гына килгән *Өй*, һәркемне иләктән үткәрә торган *Тегермән*, сату-алу эшләре алып бара торган *Базар*, тормыш-көнкүреш өчен көрәш *Мәйданы* һ.б. булып символик чагыштыру чаралары белән күз алдына китереп бастырыла»[27]. Шулай ук шагыйрьнең табигатьтәге төрле кошларны (сандугач, лачын, һөдһөд, тавис һ.б.) символлаштыруы да игътибарга алына. Ә менә *Таң ату* – әсәрләрдә мәңгелеккә күчүне белдерә икән. Гаҗәп бит!

Социаль гаделлек һәм гомуми тигезлек идеяләре, мәгълүм булганча, борынгы суфичылык өйрәтмәләренә, ягъни суфиларның хөкемдарлар белән бик үк яхшы булмаган мөнәсәбәттә яшәгән чорларга барып тоташа[28]. Барлык иҗтимагый катлаулар тигезлеген тереклек ияләре ярдәмендә сурәтләүнең әүвәлге үрнәкләрен без фарсы әдәбиятында IX–X йөзләрдә, төрки әдәбиятта Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» хезмәтендә, Йосыф Баласагуниның «Котадгу белек» әсәрендә (XII) үк очратабыз. Татар әдәбиятында XX гасыр башына кадәр уңышлы дәвам иттерелгән бу метафорик сурәтләү чарасының, хезмәттән күренгәнчә, Өмми Камал иҗатында да кулланылуы поэтик традицияләрнең өзлексез һәм тотрыклы эволюцион үсеше хакында сөйли булса кирәк.

Борынгы һәм урта гасыр фарсы һәм төрки язма ядкярләрдә эчтәлеге һәр авторда үзенчә тасвирланган, әмма традицион формасы сакланган, тамырлары белән суфичылык әдәбиятына барып тоташа торган бер элегия бар[29]. Ул – барлык социаль катлауларның да үлем каршында тигезлеге. Хезмәттән күренгәнчә, бу тема Өмми Камал иҗатында да чагылыш тапкан. Шагыйрь, әлбәттә, элгәреге каләмдәшләре кебек үк, үзенең идея-эстетик идеалына ярашлы рәвештә аны мөстәкыйль иҗади эшкәрткән.

Әсәрләр гамәлдәге татар хәрефләрендә бирелгән. Бу, бер яктан, киң гавам укучысын шагыйрь иҗаты белән таныштыруны җиңеләйтә, икенче яктан, татар текстологиясен үстерүгә ярдәм итә.

Текстлар Сафакүл нөсхәсеннән алынган һәм анда булмаган кайбер шигырьләр басма китаптан алып тулыландырылган. Кулъязманың факсимилесе һәм азакта сүзлек бирелү тюркологиядә кабул ителгән таләпләр нигезендә башкарылган.

Гомумән, Ф. Фәтхтдиновның бу хезмәте урта гасыр татар әдәбиятын, аерым алганда Өмми Камал иҗатын өйрәнүдә хәзерге чор филологик медиевистикада һәм тюркологиядә зур казанышларның берсе булып тора.

**Сведения об авторах:** Исламов Рамил Фанавиевич, доктор филологических наук, главный научный сотрудник Центра энциклопедистики Института Татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, e-mail: usman.58@mail.ru; Габдулхакова Гульшат Мансуровна, научный сотрудник Центра изучения татарской диаспоры Института татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, e-mail: sofa-hakova69@mail.ru.

**Аннотация.** В статье анализируется новое издание «Книги Умми Камала», составленное кандидатом филологических наук, литературоведом-медиевистом Ф.К. Фатхтдиновым. Подробно освещаются такие проблемы, как личность и творчество Умми Камала, научное отношение к ним; философско-этические основы поэзии Умми Камала; художественно-эстетическое воплощение философских взглядов поэта.

**Ключевые слова:** Умми Камал, Ф.К. Фатхтдинов, жанровая особенность, социальная справедливость, суфийская литература, средневековая татарская литература, медиевистика.

**Abstract.** The article analyzes a new edition of the «Book of Ummi Kamal», compiled by a Candidate of Philological Sciences, literary scholar-medievalist F.K. Fatkhtdinov. Such problems as the personality and creativity of Ummi Kamal, the scientific attitude to them, the philosophical and ethical foundations of Ummi Kamal’s poetry, the artistic and aesthetic embodiment of the poet’s philosophical views are highlighted in detail in it.

**Key words:** Ummi Kamal, F. Fatkhtdinov, genre peculiarity, social justice, Sufi literature, medieval Tatar literature, medieval studies.

## ИСТОЧНИКИ И ЛИТЕРАТУРА

1 Кадыйрова Э.Х. Өмми Камал әсәрләренең Казан нөсхәләре // Татар әдәбияты текстологиясе мәсьәләләре (Урта гасырлар – XX йөз башы) / Җаваплы мөхәррир Н.Ш. Хисамов. – Казан, 2006. – Б. 29–34.

2 Дмитриева Л.В. Описание тюркских рукописей Института востоковедения. – М.: Гл. ред. восточ. лит-ры изд-ва «Наука», 1980. – С. 44–45.

3 Булгаков Р.М., Галяутдинов И.Г. Описание восточных рукописей Института истории, языка, и литературы. – Уфа: Гилем, 2009. – С. 118–122.

4 Өмми Кәмал. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр Оренбург өязе Каргалының Гомәр Габдерәхим угылы Мостафинның хәраҗәте илән 1884 нче елда. – 113 б.

5 Китабе Өмми Кәмал. Бу китап басма улынмыштыр Казанда Чирков хатынының вәрсәләренең табыгханәсендә Мөхәммәтҗан вә борадәре Шәрифҗан әл-Кәримиләрнең хәраҗәте илән 1898 нче елда. – 112 б.

6 Китабе Өмми Кәмал. Бу китап басма улынмыштыр Казанда Домбровскийның табыгхансендә Мөхәммәдгали бине Минһаҗеддин әл-Казаниның мәсрафы илән 1899 нчы елда. – 157 б.

7 Өмми Кәмал. Мабагаи Кәримия Казанда кәнде мәсарыфлары илә 1906 сәнә. – 112 б.

8 Умму Камал (XV нчи юз йыл) // Алиев С.М.-С., Акаев М.-Г.Д. Революциядан алдагъы къумукъ адабият. Хрестоматия. – Махачкала, 1980. – Б. 33–40; Абдуллатипов А.Ю., Шабаева Л.А. Средневековая литература кумыков. – Махачкала, 2011. – С. 64–67.

9 Гали М. Өмми Камал китабы // Совет әдәбияты. – 1941. – № 5. – Б. 41–63.

10 Шунда ук. – Б. 63.

11 Абилов Ш. XV йөзнең икенче һәм XVI йөзнең беренче яртысында әдәбият // Борынгы татар әдәбияты / Төз.: Х. Мөхәммәтов, Х. Хисмәтуллин, Ш. Абилов, Ү. Беляева, С. Исәнбаев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. – Б. 342.

12 Абилов Ш.Ш. Әдәби мохит һәм ядкярләр // Татар әдәбияты тарихы: алты томда / Җаваплы редактор Абилов Ш.Ш. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 1 т. – Б. 290–291.

13 Миңнегулов Х. Казан ханлыгы чоры язма мәдәнияте // Мирас. – 1993. – № 12. – Б. 28.

14 Татар поэзиясе антологиясе: ике китапта / Төз. Г. Рәхим. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – I кит. – Б. 129–130.

15 Ахунов А.М. Өмми Камал // Татар энциклопедиясе: 6 томда. – Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты, 2014. – 4 т.: М–П. – Б. 491; Ахунов А.М. Умми Камал // Татарская энциклопедия: в 6 т. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2014. – Т. 6: У–Я. – С. 25.

16 Хусаинов Г.Б. Умми Камал // Башкирская энциклопедия: в 7 т. – Уфа: Башк. энцикл., 2010. – Т. 6: Советы народного хозяйства–У. – С. 421.

17 Хөсәйенов Ғ.Б. Өмми Камал // Башҡорт әҙәбиәте тарихы: 6 томда. – Өфө: Башҡорт. кит. нәшр., 1990. – 1 т. – Б. 252–257.

18 Миңнегулов Х. Казан ханлыгы чоры язма мәдәнияте // Мирас. – 1993. – № 11. – Б. 34.

19 Фәтхетдинов Ф. Гөлне күрде дә (XV гасыр шагыйре Өмми Кәмал турында) // Тулпар. – 1998. – № 1. – Б. 18–19; Фатхтдинов Ф.К. Некоторые особенности изучения творчества Умми Камал // Проблемы изучения и преподавания филологических наук: сб. материалов Всерос. науч.-практ. конф. 11–13 мая 1999 г.: в 4-х ч. Ч. IV / Под общ. ред. И.Е. Карпухина. – Стерлитамак: Стерлитамак. гос. пед. ин-т, 1999. – С. 9–14; Фәтхетдинов Ф. Өмми Камал иҗатын өйрәнүнең кайбер үзенчәлекләре // Вестник Башкир. гос. пед. ун-та. Сер. Гуманитарные науки. – 2000. – № 1. – Б. 76–81; Өмми Кәмал иҗатын өйрәнүнең торышы // Башкортстанда татар теле һәм әдәбиятын укытуда региональ компонент (респ. фәнни-практ. конф. 4 апрель 2000 ел): фәнни-метод. мәкал. – Стәрлетамак: Стәрлетамак дәүләт педаг. ин-ты нәшр., 2001. – Б. 51–63; Фәтхетдинов Ф. Өмми Кәмал поэзиясенең фәлсәфи-эстетик нигезләре // Проблемы изучения и преподавания тюркской филологии: преемственность поколений: сб. материалов междунар. науч.-практ. конф., посвящ. 80-летию академика М.З. Закиева и 10-летию кафедры татарской и чувашской филологии.г. Стерлитамак, 18–20 сентября 2008 г. / Науч. ред. М.В. Зайнуллин. – Стерлитамак: Стерлитамак. гос. педаг. акад. им. Зайнаб Биишевой, 2008. – Б. 258–264; Фәтхетдинов Ф. XV гасыр шагыйре Өмми Кәмал иҗатының үзенчәлекләре // Проблемы изучения и преподавания тюркской филологии: история, современность, перспективы: сб. материалов всерос. науч.-практ. конф. с междунар. участием, посвящ. 125-летию гос. и общ. деятеля, языковеда и классика татар. лит-ры Галимджана Ибрагимова, 105-летию народного поэта Чувашской Республики Петра Хузангая, 15-летию кафедры татарской и чувашской филологии СГПА им. З. Биишевой, г. Стерлитамак, 24–26 мая 2012 г. / Науч. ред. И.С. Насипов. – Стерлитамак: Стерлитамак. гос. педаг. акад. им. З. Биишевой, 2012. – Б. 256–259; Татар әдәбияты тарихы: 8 томда / Төз. һәм җаваплы мөхәррире Р.Ф. Рахмани. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 2 т. – Б. 31–44; Фатхтдинов Ф.К. Философско-эстетические основы поэзии Умми Камала // Тюркская филология в XXI веке: проблемы и перспективы: сб. материалов всерос. науч.-практ. конф. с междунар. участием, г. Стерлитамак, 21 марта 2014 г. / Науч. ред. И.С. Насипов. – Стерлитамак: Стерлитамак. филиал БашГУ, 2014. – С. 331–338; Фатхтдинов Ф.К. Рукописи произведений Умми Камала – бесценное наследие татароведения // Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика: I ме-

ждунар. науч.-практ. семинар. 2–3 декабря 2021 г., г. Казань: сб. материалов. – Казань: ИЯЛИ, 2021. – С. 194–197.

20 Фатхтдинов Ф.К. Творчество поэта XV века Умми Камала (художественные и философско-этические проблемы): автореф. дис. … канд. филол. наук; БашГУ. – Уфа, 2002. – 23 с.

21 Фәтхтдинов Ф. Өмми Кәмал – суфи шагыйрь. – Уфа: Китап, 2015. – 160 б.

22 Фәтхтдинов Ф.К. Өмми Кәмал иҗаты: Уку әсбабы / Фәнни мөхәррире: Дәүләтшин К.С. – Уфа: БДПУ нәшр., 2008. – 120 б.

23 Фатхтдинов Ф.К. Книга Умми Камала = كتاب امى كمال = Өмми Камал китабы (на русском, старотюркском (рукопись, транскрипция рукописи), татарском языках) / Науч. ред. К.С. Давлетшин. – Казань: ИЯЛИ, 2022. – 648 с.

24 Там же. – С. 123.

25 ТР ФАнең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать инстиуты Язма һәм музыкаль мирас үзәге: 39 тупл., 1 тасв., 338 саклау берәм.

26 Фатхтдинов Ф.К. Книга Умми Камала = كتاب امى كمال = Өмми Камал китабы (на русском, старотюркском (рукопись, транскрипция рукописи), татарском языках) / Науч. ред. К.С. Давлетшин. – Казань: ИЯЛИ, 2022. – С. 98.

27 Там же. – С. 119.

28 Айзенштейн Н. Несколькло наблюдений над литературным памятником анатолийских сельджуков «Житие Бахаэддина Веледа» (из «Жизнеописаний святых») А. Эфляки)» // Советская тюркология. – 1976. – № 3. – С. 52.

29 Исламов Р.Ф. Об одном элегическом в тюркских письменных литературных памятниках средневековья // Гуманитарные науки в Башкортостане: история и современность: материалы междунар. науч.-практ. конф., посв. 75-летию ИИЯЛ УНЦ РАН. 16 ноября 2007 г. – Уфа: Гилем, 2007. – С. 105–107.